# Халык депутатларының XXI чакырылыш Октябрь район Советына 1990 елның 4 мартында сайланган депутатлар исемлеге

| Сайлау округларының исеме һәм номеры | Депутатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Эш урыны, шөгыле |
|---|---|---|
| 6. Богдашкино | Аввакумов Владимир Ильич | «Правда» колхозының азык җитештерү буенча аренда звеносы җитәкчесе. |
| 41. Якушкино | Акмурзин Леонид Алексеевич | «Родина» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире. |
| 22. Яңа Иглай | Атауллин Харис Нуруллович | «Рассвет» совхозы директоры. |
| 21. Мамык | Багаев Николай Николаевич | Мамык урта мәктәбе укытучысы. |
| 25. Сәләнгеш | Баранов Александр Иванович | «Заветы Ильича» колхозы председателе. |
| 30. Урта Камышлы | Белогубов Сергей Ильич | Синдряков исемендәге колхоз председателе. |
| 18. Түбән Норлат | Бикинеев Айдар Шакирович | «Кондырча» махсус хуҗалык арендаторы. |
| 45. Норлат—Завод | Богатиков Владимир Васильевич | Халык депутатларының район Советы башкарма комитеты председателе. |
| 31. Бикүле | Вәлиуллин Тәлгать Гобәйдуллович | Муса Җәлил исемендәге колхоз башлангыч партия оешмасы секретаре. |
| 35. Төрнәс совхозы | Винокурова Евгения Геннадьевна | Төрнәс урта мәктәбе укытучысы. |
| 53. Норлат—Нефтяник | Гаврилов Петр Петрович | НУРБның скважиналарны сынау цехы шоферы. |
| 43. Норлат—Комсомольск | Газизуллина Любовь Никифоровна | Норлат тимер юл станциясе начальнигы. |
| 2. Әмзә | Галимов Әүхәт Әсхәтович | «Комбайн» колхозы арендаторы. |
| 38. Биккол | Галимов Фатыйх Миннеханович | Халык контроленың район комитеты председателе. |
| 37. Фома | Галимов Фәрит Шәяхмәтович | КПСС райкомының оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге мөдире. |
| 28. Иске Әлмәт | Гарифуллин Әдһәм Әнвәрович | XXI партсъезд исемендәге колхоз председателе. |
| 3. Кызыл Юл | Гаянов Илсур Нәгыймович | Кызыл Юл урман пункты начальнигы. |
| 47. Норлат—Маяковский | Гыйззәтуллина Рәмзия Шакировна | Норлат шикәр заводы каршындагы чөгендер пункты хисаплау машинасы операторы. |
| 8. Үрнәк | Даутов Вахит Мостафович | Ульянов исемендәге колхоз председателе. |
| 24. Яңа Тумба | Захаров Николай Михайлович | Лесозавод урта мәктәбенең уку-укыту бүлеге мөдире. |
| 23. Ключи | Екамасова Галина Николаевна | «Рассвет» совхозы дуңгыз караучысы. |
| 60. Норлат—Мәктәп | Емелина Татьяна Витальевна | «Кооппродторг» сатучысы. |
| 1. Аксумла | Еремеев Георгий Григоьевич | АПК работниклары профсоюзының «Большевик» колхозы председателе. |
| 26. Урта Камышлы | Иванова Вера Алексеевна | Урта Камышлы урта мәктәбе укытучысы. |
| 44. Норлат—Куйбышев | Иванов Юрий Сергеевич | Ульяновск депосының Норлат филиалы тепловоз машинисты. |
| 13. Берлек-Михайловка | Ильин Федор Иванович | «Лесная Поляна» махсус хуҗалыгы председателе. |
| 12. Елаур | Кадушкина Надежда Евгеньевна | Знамя Октября»колхозы сыер савучысы. |
| 32. Кәкре Атау | Кәлимуллин Рәшит Ризванович | Муса Җәлил исемендәге колхозның икенче комплексы бригада бригадиры. |
| 50. Норлат—Беренче Май | Камалетдинова Асият Далгатовна | Сөт-май комбинатының өлкән мастеры. |
| 55. Норлат—Тельман | Камалетдинов Сәлимгәрәй Марсиҗанович | Октябрь ремтехпредприятиесе слесаре. |
| 29. Иске Чаллы | Коростелев Александр Аркадьевич | КПСС райкомы секретаре. |
| 27. Абляскино | Маланьин Валерий Аркадьевич | Мичурин исемендәге колхоз терлекчесе. |
| 11. Каравыл Тавы | Макаров Алексей Владимирович | «Россия» колхозы шоферы. |
| 7. Киекле | Мингалимов Усман Исламович | Ульянов исемендәге колхоз председателе урынбасары. |
| 19. Югары Норлат | Мөлеков Әхмәт Вәлиәхмәтович | КПСС райкомының икенче секретаре. |
| 46. Норлат—Циалковский | Мөлеков Наил Бариевич | МСО начальнигы. |
| 40. Зирекле | Миназов Әхмәтнәкыйп Нурмиевич | Элеватор директоры. |
| 36. Төрнәс | Мишина Таисия Петровна | Төрнәс фельдшер-акушерлык пункты мөдире. |
| 16. Кормыш | Морадыймов Хәлил Хәмзиевич | КПСС райкомының беренче секретаре. |
| 17. Колбай Мораса | Мотаһиров Сөләйман Мәрдиевич | «Алга» колхозы председателе. |
| 20. Чуваш Мәнҗесе | Мөхәммәтҗанов Илшат Исхакович | Хафизов исемендәге колхоз председателе. |
| 52. Норлат—Дружба | Мөхәрмәтов Юнир Гобәйдуллович | НУРБ начальнигы. |
| 14. Заречный | Назарова Тамара Анатольевна | Халык депутатларының район Советы башкарма комитеты секретаре. |
| 42. Салдакай | Ногманова Флюра Рәшидовна | Салдакай урта мәктәбе директоры. |
| 15. Кычытканлы | Нургалиев Җәүдәт Заһитович | «Татарстан» колхозы председателе. |
| 33. Илюткино | Пакшин Геннадий Кузьмич | АПК профсоюзлары район комитеты председателе. |
| 56. Норлат—Совет | Палькейкина Раиса Алексеевна | Норлат машина төзү заводы калайчысы. |
| 49. Норлат—Куйбышев | Петров Иван Иванович | Пенсионер. |
| 5. Биләр Озеро | Савинов Евгений Кузьмич | «Путь к коммунизму» колхозы председателе. |
| 57. Норлат—Прәмышленный | Савинов Александр Иванович | «Татагропроммехмонтаж» трестының Норлат-Октябрь ПМКсы электромонтаж эшләре мастеры. |
| 34. Чуваш Тимерлеге | Сашин Валентин Николаевич | Тимерлек урта мәктәбе укытучысы. |
| 4. Андреевка | Тарасов Владимир Васильевич | «Восход» колхозы председателе. |
| 10. Егоркино | Терентьев Юрий Владимирович | «Россия» колхозы председателе. |
| 51. Норлат—Үзәк | Ухванов Эдуард Юрьевич | «Норлатнефть» НГДУсы ПРЦЭОсының слесарь-ремонтчысы. |
| 59. Норлат—Гагарин | Хуҗин Марат Мөхлисович | «Норлатнефть» НГДУсы начальнигы. |
| 58. Норлат—Шашин | Шабаев Зәкәрия Абдуллович | Район үзәк больницасының баш врачы. |
| 9. Кизләү | Шәйхетдинов Хәлил Хәмзиевич | «Чишмә» колхозы председателе. |
| 48. Норлат—Линейный | Чахмахчев Роман Савич | Ит комбинаты директоры. |

**«Татарстан АССР халык депутатларын сайлаулар турында»гы Законның 53 статьясына нигезләнеп, 39, 54 сайлау округлары буенча яңадан сайлаулар үткәреләчәк.**

**РАЙОН САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ.**

● Сүзебез энтузиастлар турында

## Мавыгучан кеше



Андый кешеләр бик еш очрамый. Аларның иҗади инициативасыннан, ианганлыгыннан, профессиональ белеменнән туа да инде кызыклы эшләр. Норлат разведка бораулавы идарәсе каршындагы спорт комплексы директоры Владимир Константинович Киселев нәкъ әнә шундый сыйфатларга ия.

Аның оештыру сәләте мәктәп елларында ук ачылды. Бер генә спорт чарасы да аның катнашыннан башка үтми иде. Ул үз тормышының һәр этабында алдына конкрет максат куйды һәм аңа ирешү өчен көчен кызганмады. Аңа даими эзләнүләр, эш алымнарын камилләштерү хас. В. К. Киселев яшь буынга физик тәрбия бирү өлкәсендә байтак эшләр башкара. Спорт комплексы директоры буларак, ул спортка карата кызыксыну тәрбияли. Эшче яшьләрне системалы төстә занятиеләргә тарту, аларның буш вакытларын файдалы үткәрүне оештыру һәм башка проблемаларга зур әһәмият бирә. Ул «Һәркем өчен һәм һәркем белән эшләргә» дигән принцип буенча яши. Бу аңа балаларның ихтирамын казанырга ярдәм итә. Һәм аңа физик тәрбия бирү, балаларны ярату, үз эшенә иҗади якын килү яшьләрнең остазы булырга булышты.

Иптәш Киселев үзе үткәрә торган занятиеләрнең эстетик ягына зур әһәмият бирә. Аның занятиеләре уен һәм ярышлар нигезендә эмоциональ үтә. Ул эшли торган залның чисталыгы, пөхтәлеге, балаларның бер үк киемдә булулары һәм шулай ук укытучының шәхси пөхтәлеге күңелләрне күтәрә. Аның методик эшне дөрес оештыруы, тыйнаклыгы, балаларның тәртибе һәм занятиеләргә җаваплы карашлары эшнең башлангычын хәл итә. Моны иптәш Киселев үзе дә нәкъ шулай дип бәяли. Ул методик эшкә күп көч куя, спорткомплекс укытучылары белән үзенең бай тәҗрибәсен теләп уртаклаша. Әгәр берәү коллектив членнарын урынсыз җәберләсә, ул аларны якларга әзер тора, кешеләрне эшкә команда бирмичә туплый белә.

Ул шулай ук мактый да, кирәк чакта тәнкыйть уты астына да ала, эшкә намуслыларны һәм активларны тиз күрә белә.

Коллективның һәр членын мөмкинлекләренә һәм интересларына карап эшкә туплый. Коллектив членнары моңа үзләре дә яхшы эшләре белән җавап бирәләр, ул оештырган һәр эштә катнашырга әзер торалар.

Барлык бу сыйфатлар Киселевка хас. Иң мөһиме, ул кешеләргә ышана. Билгеле, кешеләр дә ышанычка ышаныч белән җавап бирәләр. Коллектив аны гадел, намуслы, игътибарлы, даими эзләнүчән буларак яхшы аңлый. Көндәлек шәхси үрнәкләре һәм зур профессиональ эрудициясе спорткомплекс тормышын кызыклы итә.

Рәсемдә: спорткомплекс директоры В. К. Киселев шахмат уены вакытында.

## Хезмәтенә күңелен биреп

Илдар Камалетдинов февраль аенда 42 баш үгездән 1292 шәр грамм үсеш алды. Бу уңыш тырышып, бөтен көчеңне биреп эшләүдән килә. Ул җиде елдан артык терлекләр белән эшләү дәверендә шактый тәҗрибә туплады. Җәй башыннан терлекләрне көтүгә дә үзе алып чыга. «Хайваннар яхшы ашатылмаса, күңелем һаман тыныч түгел», —ди Илдар. Һичшиксез, үз хезмәтенә җанын биреп эшләгән кеше генә әйтә ала мондый сүзләрне. Аның тормыш иптәше дә сыер савучы. Хәзерге вакытта бергәләп ике бала тәрбиялиләр.

**М. АЛИЕВ,**
Муса Җәлил исемендәге колхоз.

